**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш. Совет майданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района**
**Республики Татарстан**
**Совет города Арск**
**422000,г. Арск, площадь Советская , 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

## Арча шәһәр Советы карары

**« 20 » декабрь 2018 ел** **№ 113**

### Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә Җәмәгать тыңлауларын (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. Арча шәһәр Советының 13.09.2018 №99 карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. Гавами тыңлауларның инициаторлары».

Гавами тыңлаулар халык инициативасы белән, Арча шәһәр Советы (алга таба - Совет), «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы (алга таба - башлык) яисә үз вәкаләтләрен контракт нигезендә гамәлгә ашыручы Арча шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан үткәрелә.

2) 5 статьяның 1 өлешендәге 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. Гавами тыңлауларны билгеләү".

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы яисә, үз вәкаләтләрен контракт нигезендә башкаручы Арча шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә.

2. Әлеге карарны Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адрес һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Карар рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Арча шәһәре муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г. Нуриев